Әлмәт шәһәр Башкарма комитеты

22 апрель 2020 ел №52

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының
«Территорияне ызанлау проектын
әзерләү турында» 2020 елның 15
апрелендәге 49 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Территорияне ызанлау проектын әзерләү турында» 2020 елның 15 апрелендәге 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктта «үз акчалары хисабына» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең җирле бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;
- 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.


3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Вәлиев

Әлмәт шәһәр Башкарма
комитетының 2020 елның
«22» апрель  № 52 карарына
1 нче кушымта

Ызанлау территориясе чикләре




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косарев